Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Өчкүл авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 14-1 13.01.2026

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Өчкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге Советының 2018 елның 03 маендагы 54-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында "2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Спас муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы Рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 23 апрелендәге 26-1 номерлы Спас муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 4-2 номерлы Спас муниципаль районы Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге Советы

<u>КАРАР ИТТЕ:</u>

1. Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Өчкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 03 маендагы 54-3номерлы карарына (Өчкүл авыл җирлеге Советының 2018 елның 06 июнендәге 54-2 номерлы, 2018 елның 03 декабрендәге 66-2 номерлы,2020 елның 03 сентябрендәге 117-2 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 60 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 64-3 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 113 номерлы, 2024 елның 30 октябрендәге 123-2 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге

2

139-2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «15389 "саннарын «16928" саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында //http:pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Өчкүл авыл җирлеге башлыгы Н.В. Емелюшина

СОВЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Өчкүл авыл җирлеге Советының 2018 елның 03 маендагы 46-1 номерлы карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге Советының 2026 елның 13 гыйнварындагы 14-1 номерлы карары редакциясендә)

Өчкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16931 |
| Депутатлар | 16928 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16928 |